Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Сүлә торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

07.11.2019 № 1

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 25.10.2009 ел, № 25 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең Сүлә торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2020 нче елда Саба муниципаль районының Курсабаш авыл җирлеге Сүлә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 4000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Сүлә авылында җирләү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/korsabash бастырып чыгарырга.

Курсабаш авыл
җирлеге башлыгы А.Р. Гыймадиев